КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 август г.Казань № 698

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 ел, 9 февраль, 67 нче карары белән расланган Авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр түләү бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 ел, 9 февраль, 67 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 25 июнь, 507 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр түләү бирү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү түбәндәгеләргә бирелә:

мөрәҗәгать итү датасына кимендә өч ел Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче 25 яшькә кадәрге хатын-кызларга беренче баласы туганда;

мөрәҗәгать итү датасына кимендә өч ел Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче 29 яшькә кадәрге хатын-кызларга өченче баласы туганда;

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән хатын-кызлар үлгән очракта, аларның ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән (ата-ана хокукларын чикләү) бала туган очракта бер тапкыр түләү баланың атасына (опекунга) бирелә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Бала туганда бер тапкыр түләнә торган түләүне билгеләү өчен әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар яки Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең яшәү урыны буенча бүлегенә (алга таба - Үзәк бүлеге) тапшыралар:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча, банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, бала туганда бер тапкыр түләнә торган түләүне билгеләү турында гариза (алга таба – гариза);

бала (балалар) туу турында таныклык күчермәсе – Татарстан Республикасыннан читтә бала (балалар) туу акты теркәлгән очракта;

ана (ата) үлеме турында таныклык күчермәсе – Татарстан Республикасыннан читтә үлем акты теркәлгән очракта;

Татарстан Республикасы территориясендә кимендә өч ел авыл җирендә, шәһәр тибындагы бистәләрдә даими яшәү фактын билгеләү турында судның законлы көченә кергән карарының күчермәсе - гариза белән мөрәҗәгать иткән датага кимендә өч ел Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда яшәү урыны буенча теркәлмәгән очракта;

вәкаләтле затлар өчен ышанычнамә күчермәсе.

Гариза белән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ тапшырыла.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган очракта, алар оригиналлар күрсәтеп тапшырыла һәм үзәкнең бүлек белгече тарафыннан раслана.

Почта аша гариза җибәргәндә аңа кушып бирелә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланырга тиеш.»;

7 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Нигезләмәнең 6 пунктындагы бишенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, Татарстан Республикасы территориясендә кимендә өч ел авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәү фактын раслый торган белешмәләр.»;

8 пунктта «бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү турында гариза» сүзләрен «гариза» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин